ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» декабрь 2019 ел. № 470

2020 елга Әгерҗе муниципаль районында
балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге
өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 ел, 14 декабрь, 854нче карары һәм Татарстан Республикасы “Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга расларга (кушымта итеп бирелә):

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә 0,5 күләмендә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициенты.

2.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://agryz.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гильмутдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.С. Авдеев**

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
06 декабрь 2019ел, 470 номерлы
Карары белән

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (бер укучыга бер елга сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | Биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | иртә һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | Шәһәр җирлеге | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыкаль сәнгать | Авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | Шәһәр җирлеге | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Сынлы сәнгать | Авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореографик сәнгать | Шәһәр җирлеге | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Хореографик сәнгать | Авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | Шәһәр җирлеге | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | Авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгать | Шәһәр җирлеге | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгать | Авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Шәһәр җирлеге | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театраль сәнгать | Шәһәр җирлеге | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театраль сәнгать | Авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |